
# Галим Риза Фәхретдиннең «Нәсыйхәт» китабыннан:



- үз урыныңда авышмыйча дөрес утыр;
- дәрескә күңел сал;
- сораган сүзне дөрес аңлап, ачык тавыш белән җавап бир;
- укытучының һәр сүзен мәхәббәт белән үтә.

# СҮЗ ТӨРКЕМЕ - ИСЕМ

- предметны белдерә
- кем? нәрсә?
- сан
- килеш
- җөмләдә баш кисәк - ия

# ИСЕМНӘРНЕҢ КИЛЕШ БЕЛӘН ТӨРЛӘНЕШЕ

| килешләр | сораулар | кушымчалар |
|---|---|---|
| Баш килеш | кем? нәрсә? | - |
| Иялек килеше | кемнең? нәрсәнең? | -ның, -нең |
| Юнәлеш килеше | кемгә? нәрсәгә?кая? | -га, -гә, -ка, -кә |
| Төшем килеше | кемне? нәрсәне? | - ны, -не |
| Чыгыш килеше | кемнән? нәрсәдән? кайдан? | -дан, -дән, -тан, -тән |
| Урын –вакыт килеше | кемдә? нәрсәдә? кайда? | -да, -дә, -та, -тә |

# БАБАЙ,КӨРӘК ӘТИ,УРЫНДЫК

| **килешләр** |
| --- |
| Баш килеш |
| Иялек килеше |
| Юнәлеш килеше |
| Төшем килеше |
| Чыгыш килеше |
| Урын-вакыт килеше |

| | |
| --- | --- |
| бабай | әти |
| бабай ның | әти нең |
| бабай га | әти гә |
| бабай ны | әти не |
| бабай дан | әти дән |
| бабай да | әти дә |

# ТИЕШЛЕ КИЛЕШ КУШЫМЧАЛАРЫН КУЯРГА

Бакча безнең ил,
Алтын безнең җир,
Җир гә тезләнеп,
Чәчәк өздем мин.

Менә шул чак та
Җир не кочаклап
Үбәсем килде, -
Сыймый кочак ка.

Йөрәк кә сыйды,
Туйганчы сөйдем:
“Йөрәгем дә кал
Мәңгегә!” – дидем. (Бари Рәхмәт)

# ТЕСТ.СҮЗ ТӨРКЕМЕ - ИСЕМ

1. Исем –

   а)җөмлә кисәге; б)сүз төркеме; в)сүз өлеше

2. Исемгә туры килгән билгеләмәне күрсәт:

   а) предметны белдерә;

   б) предметның эшен,хәрәкәтен белдерә;

   в) предметның билгесен белдерә;

   г)предметның санын белдерә.

3. Исем нинди сорауларга җавап бирә?

   а) нишли?,нишләде?, нишләр?

   б)кем? нәрсә?

   в) нинди? кайсы?

   г)ничә? күпме?

4.Урманның сүзе нинди килештә:

а)баш килешендә;

б) төшем килешендә;

в) иялек килешендә;

г) урын – вакыт килешендә.

5. Салкын җилләр очып кил…

Туган якка – кунакка.

Кил сүзенә нинди кушымчаны куярга кирәк?

а) -ды б) - ты

в) – де г) - те

# ҖАВАПЛАР

| № | а | б | в | г |
|---|---|---|---|---|
| 1 | | + | | |
| 2 | + | | | |
| 3 | | + | | |
| 4 | | | + | |
| 5 | | | + | |

# ӨЙ ЭШЕ

- 117 нче күнегү.Тиешле кушымчаларны өстәп,җөмләләрне күчереп яз.Килешләрне билгелә.
- Килешләрне кабатла 47бит.